**Рус телендә гомуми урта белем бирү оешмаларының татар төркемнәрендә белем алучы 8 нче сыйныф укучыларына татар әдәбиятыннан муниципаль тур өчен олимпиада сорауларына җаваплар**

Максималь балл – **45**.

**1. Татар халык авыз иҗатының кайсы жанры турында сүз баруын языгыз (2 балл):**

- Шәрык әдәбиятында һәм фольклорында лирик жанр атамасы, дини эчтәлекле әсәр;
- ялгызлыкта үз-үзең белән сөйләшү, Аллаһы Тәгаләгә мөрәҗәгать итү, ярлыкау;
- ул гадәттә көй белән башкарыла.

**Җавап:** мөнәҗәт

**2. Хата белән бирелгән төшенчәләр рәтен күрсәтеп языгыз (2 балл):**

а) тарихи җыр, дастан, мөнәҗәт, бәет

ә) драма, комедия, трагедия, трагикомедия

б) йола һәм уен-бию җырлары, тарихи җырлар, популяр җырлар, кыска җырлар


**Җавап:** б) йола һәм уен-бию җырлары, тарихи җырлар, популяр җырлар, кыска җырлар

**3. Әдипләр портретларын һәм әсәрләргә рәсем-иллюстрацияләрне карагыз.**

**а) Язучыларны һәм аларның әсәрләренә ясалган рәсемнәрне туры китереп билгеләгез (3 балл):**

1) 2) 3)





а) ә) б)





**Җавап:** 1) ә; 2) а; 3) б.

**ә) Әсәрләрнең авторларын һәм исемнәрен языгыз (3 балл):**

**Җавап:**

Һади Такташ «Мокамай»

Әмирхан Еники «Кем җырлады»

Мөхәммәт Мәһдиев «Без – кырык беренче ел балалары»

**б) Шул әсәрләрнең берсе турында белгәннәрегезне языгыз (5 балл).**

**4. Персонажларны кайсы әсәрдән алынганлыгын билгеләгез (4 балл):**

1) Хәлим а) «Кем җырлады»

2) Гомәр ә) «Туган ягым – яшел бишек»

3) Әлтәфи б) «Онытылмас еллар»

4) Таһирә в) «Без – кырык беренче ел балалары»

**Җавап:** 1) б; 2) ә); 3) в; 4) а.

**5. Шигырьдән өзекне укыгыз. Сорауларга җавап языгыз.**

... Ә биредә, без фашистлар белән
Бугазлашкан урман-кырларда,
Күңел өчен бер генә кош та юк
Язны хәтерләтеп җырларга.

Дулкынланып, шаулап торган урман
Сынып беткән, изрәп тапталган,
Чәчәк үсә торган киң болыннар
Кеше каны белән тапланган.

Фашист тырнагына капкан кеше
Сыкрамыйча монда тын алмый,
Янган авылларның төтеннәре
Язгы таңның нурын томалый.

Фашист илгә үлем генә китерә,
Фашизмның таңы, язы юк.

Яшен уты белән күккә язып әйтәм:

Язы юкның яшәү хакы юк!

**а) Әсәрнең исеме (1 балл)___________**

**ә) Әсәрнең авторы (1 балл)__________**

**б) Исегезгә төшерегез: шигырьнең беренче өлешендә лирик герой нинди хисләр кичерә? (4 балл)**

___________________________________________________________________

___________________________________________________________________

___________________________________________________________________

**в) Әсәрдә сугыш чынбарлыгын сурәтләүдә кайсы табигать образлары ярдәмгә килә? Аларны языгыз (2 балл)**_________________________________

___________________________________________________________________

___________________________________________________________________

___________________________________________________________________

_______________________________________________________________

**г) Фашизм нәрсә ул? Ни өчен аның яшәргә хакы юк? Лирик геройның фашизмга мөнәсәбәтен билгеләгез. Сез бу фикер белән килешәсезме? Фикерләреңне нигезләгез (3 балл)** __________________________________

___________________________________________________________________

___________________________________________________________________

___________________________________________________________________

___________________________________________________________________

**Җаваплар:**

а) Бездә – яздыр

ә) Фатих Кәрим

б) Лирик герой соклану, тынычлану, сагыну хисләре кичерә.

в) Кошсыз урман-кырлар, сынып беткән, изрәп тапталган урман, кеше каны белән тапланган чәчәкләр, төтен белән капланган язгы таң нуры.

б) Лирик геройның фашизмга мөнәсәбәте катгый. Фашизм – ул иң кешелексез, иң ерткыч, кансыз күренеш. Фашизм аркасында күпме кеше һәлак булган, җәзаланган, газап кичергән. Шуңа күрә дә аның киләчәге дә, яшәргә хакы да юк.

**6. Терәк сүзләрдән файдаланып, зур булмаган инша языгыз (15 балл).**

*Өмә, күмәк, күңелле, бергәләп, җырлый-җырлый, күңел ачу, эш-хезмәт, уңган, яшьләр, оештыру, көлешү, шат тавышлар, ярдәм итү, булышу*.

**Иншагызның текстында әлеге сүзләрнең сайланышы ирекле.**

**Татар әдәбиятыннан мисаллар китерергә онытмагыз.**

**Иншагызга кыска һәм мәгънәле исем бирегез. Иншаның күләме – 8-10 җөмлә.**